РУКОВОДИТЕЛЬ ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА ГОРОДА ЗАИНСКА ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЗӘЙ ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА КОМИТЕТ ҖИТЕКЧӘСЕ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

21.10.2021 г. Заинск № 159

**Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре башкарма комитетының 2015 елның 16 октябрендәге 570 номерлы карары белән расланган элек хосусыйлаштырылган торак биналарны муниципаль милеккә кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында**

Гамәлдәге законнарга туры китерү максатында, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Зәй шәһәре Уставына таянып, Зәй муниципаль районының Зәй шәһәре башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. "Элек хосусыйлаштырылган торак биналарны муниципаль милеккә кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 16 октябрендәге 570 номерлы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре башкарма комитеты карарына (кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.5 пунктны (Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен законнар яисә башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның, шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәт күрсәтүләрнең тулы исемлеге, аларны мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны тапшыру тәртибе) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) Гариза (1 кушымта);

- кәгазь документ формасында;

- региональ портал аша мөрәҗәгать иткәндә «Электрон имза турында» 2011 елның 06 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә имзаланган электрон формада;

2) Һәр гаилә әгъзасының һәм вәкилнең шәхесен раслый торган документлар;

3) Мөрәҗәгать итүченең вәкиле вәкаләтләрен раслый торган документ (мөрәҗәгать итүченең вәкиле муниципаль хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта);

4) Гражданнарның торак урыннан файдалануга хокукын раслый торган документ (ордер, торак урынга социаль наем шартнамәсе);

5) Опекунлык таныклыгының күчермәсе, әгәр торак бинада бары тик 14 - 18 яшьлек балигъ булмаган яисә хокуктан файдалануга сәләте чикләнгән гражданнар яшәсә;

6) Күчемсез милек объектының кадастр паспорты;

7) Муниципаль милек реестрыннан өземтә;

8) Элек яшәгән урыннардан түләүсез хосусыйлаштыру хокукыннан файдаланмау турында белешмә;

9) Хосусыйлаштыруда катнашудан баш тарту турында нотариаль таныкланган гариза (әгәр гаилә әгъзалары хосусыйлаштыруда катнашырга теләмәсә);

10) Мөрәҗәгать итүче гаиләсенең 14 яшькә җитмәгән барлык әгъзалары өчен туу турында таныклык күчермәләре;

11) Мөрәҗәгать итүче һәм/яисә аның гаилә әгъзалары өчен никах турында таныклык күчермәсе;

12) Ата булуны билгеләү турында таныклык күчермәсе;

13) Аерылышу турында таныклык күчермәсе;

14) Опека билгеләү турында белешмәләрнең күчермәсе.

Муниципаль хезмәт алу өчен гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Башкарма комитетка шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон формасы Башкарма комитетның рәсми сайтында урнаштырылган.

Гариза һәм аңа теркәп бирелә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан түбәндәге ысулларның берсе белән тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:

шәхсән үзе китерә (мөрәҗәгать итүче исеменнән ышанычнамә нигезендә эш итүче зат тарафыннан);

почта аша җибәрелә.

Гариза һәм документлар шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документлар рәвешендә региональ портал аша да тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.»;

1.2. 2.6. пунктны (Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнары яисә җирле үзидарә органнары ведомство буйсынуында булган оешмалар карамагындагы һәм мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге, шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар алар карамагында булган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яки оешма) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында алына:

1) Яшәү урыны буенча теркәлү турында белешмәләр – Россия ЭЭМ;

2) 2000 елның 01 гыйнварына кадәр булган күчемсез милек объектына милек хокуклары турында БТИдан белешмә.

Мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе әлеге регламентның 2.5 пункты белән билгеләнгән.

Мөрәҗәгать итүчедән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнары яки җирле үзидарә органнары ведомствосындагы оешмалар карамагында булган югарыда санап үтелгән документларны таләп итү тыела.

Мөрәҗәгать итүченең югарыда күрсәтелгән белешмәләр булган документларны тапшырмавы мөрәҗәгать итүчегә хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тормый.».

1.3. 3.4.1 пунктны (ведомствоара запросларны җибәрү) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Башкарма комитет белгече ведомствоарар хезмәттәшлек кысаларында электрон формада түбәндәгеләр турында соратып запрос юллый:

1) Яшәү урыны буенча теркәлү турында белешмәләр – Россия ЭЭМ;

2) 2000 елның 01 гыйнварына кадәр булган күчемсез милек объектына милек хокуклары турында БТИдан белешмә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза кергән вакыттан алып бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: җибәрелгән запрослар.».

1.4. 2.14 пунктны (Муниципаль хезмәт күрсәтү залына, көтү залына, муниципаль хезмәт күрсәтү турында запросларны тутыру урыннарына, аларны тутыру үрнәкләренә һәм һәр муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлар исемлегенә, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматларын урнаштыру һәм рәсмиләштерү, шул исәптән федераль законнар һәм инвалидларны социаль яклау турында Татарстан Республикасы законнары нигезендә инвалидлар өчен күрсәтелгән объектларның үтемлелеген тәэмин итүгә карата таләпләр) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазландырылган биналарда һәм бүлмәләрдә башкарыла.

Гариза бирүчеләрне кабул итү урыннары документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмати стендлар белән җиһазландырыла.

Инвалидларның муниципаль хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыксыз керә алуы тәэмин ителә (бинага уңайлы керү-чыгу һәм хәрәкәт итү).

Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматы гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла.

2. Инвалидларны социаль яклау турында Россия Федерациясе законнары нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтү урынына каршылыксыз керү максатларында түбәндәгеләр тәэмин ителә:

1) күрү сәләте һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү функциясе бозылулары булган инвалидларны озата бару һәм аларга ярдәм күрсәтү;

2) транспорт чарасына утырту һәм аннан төшерү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып;

3) инвалидларның тоткарлыксыз хезмәт күрсәтүләрдән файдалануын тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат туплагычларны, аларның яшәеш мөмкинлеге чикләнүне исәпкә алып, тиешенчә урнаштыру;

4) инвалидлар өчен кирәкле тавыш һәм күрү мәгълүматын, шулай ук язуларны, билгеләрне һәм башка текстлы һәм график мәгълүматны Брайль рельеф-ноктaлы шрифты белән башкарылган билгеләр белән кабатлау;

5) сурдотәрҗемәче һәм тифлосурдотәрҗемәче хезмәтенә рөхсәт итү;

6) махсус өйрәтелүен раслый торган һәм Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Озатып йөрүче этне махсус укытуны раслый торган документ формасын һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән билгеләнгән тәртиптә һәм форма буенча бирелгән документы булганда, озатып йөрүче этне бинага кертергә рөхсәт итү.

3. Регламентның 2.14.2 пункты 1- 4 пунктчаларында күрсәтелгән муниципаль хезмәт күрсәтү гамәлгә ашырыла торган объектларның һәм муниципаль хезмәт күрсәтүдә кулланыла торган чараларның инвалидлар өчен мөмкин булуын тәэмин итү өлешендә таләпләр 2016 елның 1 июленнән соң файдалануга тапшырылган яки модернизацияләнгән объектларга һәм средстволарга карата кулланыла. ».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru), Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **Р.Р. Садртдинов**

Е.В. Майорова
6 71 27

1 нче кушымта

Кемгә ____________________________________

(муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органы

____________________________________

исеме)

Кемнән

____________________________________

____________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме, паспорт мәгълүматлары, яшәү урыны буенча теркәлүе, телефон)

## Элек хосусыйлаштырылган торак биналарны муниципаль милеккә кабул итү турында гариза

Элек хосусыйлаштырылган ____ кв. метрлы торак бинаны муниципаль милеккә кабул итүегезне сорыйм.

Торак бинаның адресы: Зәй муниципаль районы, Зәй шәһәре, _________________ урамы, _________ йорт.

Гаризага түбәндәге сканерланган документлар теркәлә:

1) Гаиләнең һәр әгъзасының һәм вәкилнең шәхесен раслый торган документлар;

2) Вәкилнең вәкаләтләрен раслый торган документ (әгәр мөрәҗәгать итүче исеменнән вәкил эш йөртсә);

3) Торак бинага милек хокукын раслый торган документ (әгәр милек хокукы күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрында теркәлмәгән булса);

5) Торак бинаның техник паспорты күчермәсе;

6) Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек бүлегенең торак бинаны муниципаль милеккә тапшыру турында рөхсәте (хосусыйлаштыруда балигъ булмаган балалар катнашса).

Соралганда сканерланган документларның төп нөсхәләрен бирергә ышандырам.

| ____________ | ____________ | ____________________ |
|---|---|---|
| (дата) | (имза) | (ФИА) |